**Без, бер-беребезне күрә алмас өчен, җитәрлек дәрәҗәдә динле, ләкин бер-беребезне ярату, хөрмәт итү өчен дингә ышануыбыз җитәрлек дәрәҗәдә түгел. (Инглиз язучысы Джонатан Свифт, 1667-1745).**

# Исламны өйрәнү - дәүләт хаҗәте.

*Россия Фәннәр академиясенең көнчыгышны өйрәнү Институты Петербург филиалының төп фәнни хезмәткәре Станислав Прозоров белән "Татар дөньясы"ның махсус күзәтүчесе Ренат Беккин әңгәмәсе*

С.М.Прозоровның фәнни эшчәнлеге һәм публикацияләре "классик" ислам тарихына багышланган. Аның китаплары арасында - беренче һәм урта гасыр гарәп авторларының аңлатмалы тәрҗемәләре һәм тарихи-дини иншаларының тикшеренүләре (ан-Наубахти, аш-Шахрастани, ал-Фахри); Иранда, Гыйракта һәм Урта Азиядә шигый тарих белеме үсеше һәм тарихи чыганаклары (VIII – X нчы гасыр урталары); дини система буларак ислам (матбугатта). Күмәк эшләре арасында - С.М. Прозоров фәнни җитәкчелегендә һәм аның турыдан-туры катнашында – "Ислам. Энциклопедик сүзлек" (М., 1991); "Ислам буенча хрестоматия" (М., 1994); "Элекке Россия империясе территориясендә ислам. Энциклопедик сүзлек", 1- 4 чыгарылышын (М., 1998-2003) күрсәтеп китәргә мөмкин.

- *Әңгәмәбез башланганчы ук Станислав Михайлович "ваххабитлар" турында сорарга җыенасызмы дип кызыксынды. Мин: "Әйе, җыенам",- дип җавап бирдем.*

- Дөресен әйткәндә, "ваххабитлар" дип аталучылар җитди куркынычлык тудырмыйлар. Алар белән бары тик үз телләрендә сөйләшергә кирәк (һәм мөмкин). Белә торган кеше, "ваххабит" тарафыннан китерелгән теләсә нинди аргументка, Коръән һәм Сөннәгә нигезләнгән, каршы аргумент китерә ала. Мин, әлбәттә, "ваххабит" фразеологиясен, үзләренең пычрак ниятләрен чынга ашыру чарасы итеп кулланган җинаятьчеләрне түгел, ә "идеологик ваххабитларны" күз алдында тотып әйтәм. Андый "ваххабитлар" белән идеологик бәхәсләр алып бару файдасыз, алар белән көрәшү өчен махсус җинаять маддәсе бар. Җәмгыятьтәге тәртипсезлекләр һәм халыкның конфессиональ белеменең бик түбән дәрәҗәдә булуы - ваххабит дин таратучыларның баш союзниклары булып, алар файдасына хезмәт итә. Белемле, махсус өйрәтелгән дин таратучылар, Коръән һәм Сөннәгә таянып, кирәкле материаллар җыялар. Россиядә һәм башка илләрдәге мөселманнарның күпчелеге шәригатьнең дини һәм юридик нечкәлекләрен белмәгәнлектән, кискен фикерләр вәгазе дингә ышанучылар арасында тамыр җәя.

Мөселман руханиларының андый очракларда үзләрен бик сүлпән тотуларын аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Үзләре атаган "ваххабитлар" белән ачыктан-ачык сөйләшүләр алып барасы урынга, мөселманнарның дин башлыклары, белемгә нигезләнмәгән, ә хис-тойгыларга һәм сәяси лозунгларга таянып, гомуми тәнкыйть белән генә чикләнәләр. Эш шунда: гадәти дин белгечләре дә, дөньяви хакимият тә үзләренең белемнәре җитешмәгәнлектән, конфессиональ белемнәренең дә түбән дәрәҗәдә булганлыктан андый төр әңгәмәләргә алар әзер түгел.

- *Сезнең редакциядә чыгарылган "Элекке Россия империясе территориясендәге ислам" энциклопедик сүзлеген укыгач шуны белдем: үз вакытында (революциягә кадәр һәм революциядән соң) күренекле мөселман дин җитәкчеләре тарафыннан Урта Азиядә, Идел буенда һәм илебезнең башка регионнарында яшәүче ваххабитларга, кискен каршылыклар күрсәтелгән.*

- Әйе, ул вакытларда, гади мөселман халкы арасында зур дәрәҗәгә ия булган дин эшлеклеләре, исламдагы теләсә кайсы капма-каршылык динебезгә зарар сала, зыян китерә дип һәм исламның җирле формалары Мөхәммәд пәйгамбәребез дине рухына каршы килми дип аңлата алганнар. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: Россиянең төрле регионнарында яшәүче мөселман халкының иҗтимагый тормыш һәм дәүләт төзелеше белән үзара тәэсир итешү дәрәҗәсе, мөнәсәбәтләре төрле була. Төньяк Кавказдагы халыкның этник чуарлыгы, халыкның һәм этник төркемнәрнең тарихи аң дәрәҗәсенең төрлелеге шулкадәр ачык күренеп тора, анда исламның бердәнбер үрнәге турында сөйләшү бөтенләй мөмкин түгел. Урта Азиядә хәл башкачарак. Әгәр Төньяк Кавказ һәм Идел буе мөселманнары Россия составына кереп өлгергән булсалар, бары тик XIX нчы гасыр ахырында гына яулап алынган Урта Азия андый мөмкинчелеккә ия була алмый. Биредә секуляризация процессы, өстән-өстән һәм авырлыклар белән булса да, тиз бара. Урта Азия мөселманнары урта гасыр исламыннан яңа җәмгыятькә аяк басалар. Бу регионнар өчен суфиларның исламны таратуда һәм тамыр җәелдерүендәге рольләре зур әһәмияткә ия була. Суфичылык җирле традицияләрнең "норматив" ислам белән кушылып үрелеп китүенә аеруча җайлы форма булып чыга. Уңышсыз рәвештә гасырлар буена "бик яхшы" ислам моделен булдырырга тырышучы ислам дине белгечләре, ислам дине догматларыннан аермалы буларак, суфичылар тормышта үзара яшәүгә сәләтле "норматив" ислам һәм халык традицияләрен эшләп чыгаралар. Хәзер дөньяда суфиларның тәэсирләре булмаган ил юк диярлек. Ул, хәтта, башка илләр белән чагыштырганда аз дәрәҗәдә булса да, Сауд Гәрәбстанында да бар. Исламның региональ формаларын бергә кушу, бу процессларның

нәтиҗәсе булып тора. Региональ ислам – башка конфессияләр белән тату, тыныч яшәргә сәләтле, бу диннең үз-үзеннән канәгать яшәеш формасы. Иң әһәмиятлесе: кешеләрне тигез күреп, аларга ислам турында дөрес, төгәл информация бирү. Әлбәттә, моның белән, махсус белемнәре дә булмаган элеккеге партия хезмәткәрләре һәм этник мөселманнар түгел, ә профессиональ ислам белгечләре шөгыльләнергә тиеш.

- *Белемле ислам белгечләрен әзерләү өлкәсендә эшләр ничек тора?*

- Начар. Элек ничек әзерләмәделәр, хәзер дә андый белгечләр әзерләнми. 1988 нче елда ук, Көнчыгышны өйрәнү Институтының Ленинград бүлеге (хәзер – Санкт-Петербург филиалы) исламны өйрәнү төркеме әгъзалары көче белән исламны өйрәнү буенча махсус курс әзерләнә. Ул 1989 нчы елда "Азия һәм Африка халыклары" журналының өч санында басылып чыга. Ул гына да түгел, без ислам турында башлангыч белемне, Көнчыгышны өйрәнүче югары уку йортларында гына түгел, ә барлык иҗтимагый уку йортларында өйрәнергә кирәк дигән сорау куйдык. Әйе, соңгы вакытта кайсыбер уку йортларында исламны өйрәнү кафедралары булдырылды. Кызганычка каршы, бу шул ук совет елларындагыча "илне өйрәнү" (страноведение) кафедраларыннан артык булмый. Бу югары уку йортларында ислам турында даими рәвештә белем бирелми. Исламны өйрәнү ул - үзенең аңлы аппараты белән мөстәкыйль фән! Әгәр без исламны өйрәнү буенча югары квалификацияле белгечләр әзерли башламыйбыз икән, бик күп гомумдәүләт мөһим сораулар, даими рәвештә матбугатта һәм телевизор экраннарында очрап торган чиновник статусындагы дилетантлар һәм "ислам буенча экспертлар" тарафыннан хәл ителәчәген аңлау бик әһәмиятле. Үзләренең чыгышларында алар ирекле рәвештә "реформаторлар", "модернистлар", "салафитлар", "исламистлар", "ваххабитлар" дигән атамалар кулланып, чынлыкта исә сүз тапкырлыгы белән хирысланып, яңадан-яңа типологияләр тәкъдим итәләр. Мин бу терминнарны кулланырга ярамый дип әйтмим, ләкин бу атамаларны атаганда кем һәм нәрсә күз алдында тотылганлыкны укучыларга һәм тыңлаучыларга аңлатып бирергә кирәк. Исламда "традицияләр" һәм "яңалыклар" арасында көрәш унөч гасыр дәвамында диярлек бара бит.

Көн дә диярлек колагыбызга керә торган "ислам цивилизациясе" дигән төшенчәне алыгыз. Бу атаманы төрлебез төрлечә аңлыйбыз. Димәк, кызганычка каршы, яхшы әзерлекле ислам белгечләре юклыгы бик тә сизелә. Ислам дөньясында дәрәҗәле булып саналган әл-Азхар (Каир) кебек уку йортларында белем алган мөселман дин эшлеклеләре, әйтик, шул ук "ваххабитлар" белән сөйләшүләр алып барырлык, киң белемгә ия түгелләр.

Мөселманнарга бөтен дини сораулар буенча бер фикерлелек бәйли торган механизмның булганы юк. Ислам дөньясы идеологик планда шулкадәр төрле, бирелә төрле концепцияләргә урын җитәрлек. Исламның көче – шул күптөрлелектә.

- *Бу мөселман дөньясының беркайчан да берләшмәячәген аңлатамы?Мәсәлән, Мароккода һәм Гыйракта яшәүче ике гарәпнең, аермалыкларын да искә алып, охшаш яклары, португалияче яки алманныкына караганда күбрәк. Ислам, аның эшен дәвам иттерүчеләр өчен көчле берләштерү чарасы булып тора.*

- Әлбәттә шулай. Әгәр дә сүз исламның үз эчендәге төрлелекләр турында түгел, ә ислам һәм башка диннәр арасында икән, исламны бер бөтен дип карарга мөмкин. Ислам динендә, бөтен агымнарга да хас булган, электән үк формалашкан "диннең биш баганасы" бар (иманга килү, намаз уку, рүзә тоту, зәкят бирү, хаҗ кылу). Тарихи үзаңының төрле дәрәҗәсендәге, төрле телләрдә сөйләшүче уннарча халыклар ислам динен кабул итәләр, исламны аңлауда алар арасындагы аерымлыклар сакланачак. Бу табигый һәм гадәти хәл. Ислам турында үз фикерләрен башкаларга көчләп тагу башлану белән – бәхәсләр һәм каршылыклар туа. Замана мөмкинчелекләре белән ислам үзгәргән һәм үзгәрәчәк. Мөхәммәд пәйгамбәр, үзенең 22 ел эшчәнлеге эчендә, үзе дә үзгәргән һәм беренчел күрсәтмәләрне дә үзгәрткән (норматив намазлар санын, намазның юнәлешен, башка диндәге кешеләргә мөнәсәбәтен һ.б.). Пәйгамбәрнең Сөннәсе берничә гасырлар буена формалашкан! Йөзләрчә мең хәдисләр (Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы, эшчәнлеге, кылган гамәлләре, васыятьләре хакындагы риваятьләр, хәбәрләр) мөселман дин белгечләре тарафыннан яраксызга чыгарыла. Х нчы гасырда ук хәдисләр җыю белән шөгыльләнгәннәр. Күренекле мөселман дин белгече әл-Бухари (870 нче елда үлә), җыелган 600 мең хәдис арасыннан "әс-Сахих" җыентыгына, бик дөресләрен генә сайлап алып, бер проценттан артыграгын гына кертә. Сөннә кешеләр тарафыннан барлыкка китерелә. Хәдисләр, пәйгамбәрнең дәрәҗәсе ярдәмендә, кулланылыштагы нормаларны яктырту һәм законлаштыру, заман тудырган күпсанлы һәм күптөрле мәсьәләләрне чишү өчен кулланыла.

- *Станислав Михайлович, исламдагы төрле агым вәкилләре арасында сүз көрәштерү әһәмиятле һәм ул нәтиҗәле дә булырга мөмкин. Ә Сез төрле конфессияләр арасындагы бәхәсләргә ничек карыйсыз? Мисал өчен, Вячеслав Али Полосинның, җәмгыятьтә зур кызыксыну уяткан, "Преодоление язычества" дип аталган китабы Сездә нинди фикерләр уята?*

- Билгеле булганча, "яңа кешеләр" һәрвакыт үзләре кабул иткән диннең өстенлекләрен ихлас күңел белән вәгазьлиләр. Әгәр дә сез ислам динен кабул иткәнсез икән, дин кануннарына һәм аның рухи

байлыкларына ихлас инангансыз икән, ләкин, әле бу сезнең, гыйльми югарылыкта әңгәмә алып барырлык дәрәҗәдә икәнлегегезне аңлата дигән сүз түгел. Аннары, бер конфессиягә урта карашлы булып, икенче бер дингә түземсез булырга ярамый. Бу исламга да, христиан диненә карата да, башка конфессияләргә дә кагыла. Хәзерге заман мөселман җәмгыяте белән чагыштырганда, Аббасидлар яшәгән Урта гасыр җәмгыяте, башка диндәге кешеләргә күпкә түземлерәк булганнар: ул чагында, нәрсә белән дә булса риза булмаган үз мөселманнарын (христианнарга, яһүдләргә һ.б. караганда), күбрәк "кыйнаганнар". Шул ук вакытта, тәре походлары, инквизиция (дин дошманнарына каршы көрәшү өчен католик дине тарафыннан оештырылган һәм үзенең ерткычлыклары белән танылган хөкем итү һәм җәзалау органы), фашизм христиан дөньясында барлыкка килә...

Бик күп нәрсә җәмгыятьнең иҗтимагый мөмкинчелекләренә һәм халыкның тормыш дәрәҗәсенә бәйләнгән. Кувейтта, мәсьәлән, халыкның тормыш шартлары югары, алар моны югалтырга теләмиләр. Шуңа күрә андагы халыкны төрле экстремистик хәрәкәтләргә тарту авыр. Ә Урта Азиядә һәм Төньяк Кавказда, үзләренең күп балалы гаиләләре өчен көнлек икмәк табу авыр мәсьәлә, шуңа күрә бу регионнарда яшәүче яшь кешеләр исламның "чисталык" динен таратучыларга җиңел ышаналар һәм дини экстремизм карашларын таратуда уңдырышлы җирлек булып хезмәт итәләр. "Ваххабитларга" каршылык күрсәтүгә килгәндә, Урта Азиядә дөньяви хакимият һәм мөселман дин башлыклары экстремистларга идеологик каршылык күрсәтерлек дәрәҗәдә түгел, репрессив чаралар куллану бары тик эшне катлауландыра гына. Бу регионнарда яшәүче олы буынның җирле мөселман гореф-гадәтләре әлегә көчле булганлыктан, чит илләрдә укып кайтып, аларга "Сез Аллаһыга дөрес табынмыйсыз" дип өйрәтүчеләргә бирешмиләр. Ә яшьләр, бигрәк тә иҗтимагый яктан начар яшәүчеләр, аларга ышаналар, аларга өмет баглыйлар. Гомуми конфессиональ наданлык җирлегендә андый пропаганда үзенең ачы җимешләрен бирә.

- *Ислам белеменең кайсы өлешен Сез фәнни-популяр әдәбиятка кертер идегез?*

- Ислам белеме бүгенге көндә бик кирәк дип уйлыйм, ләкин ислам турында фәнни-популяр әдәбият әзерләү буенча профессионал ислам белгечләре шөгыльләнергә тиеш. Күптән түгел генә миңа бер нәшрияттан шалтыратып, 1991 нче елда Мәскәүдә, минем редакциядә чыгарылган "Ислам" энциклопедик сүзлектән, кыскартып, мәкаләләр бастырырга теләүләрен белдерделәр. Мин алардан, мәкаләләрне, мәгънәгә зыян китермичә, кыскарта белүче белгечләрегез бармы соң дип сорадым. Юк, ләкин сез бер дә борчылмагыз, без бик сак кыскартырбыз диләр. Кызганычка каршы, андый дәрәҗәдә бик күп

нәшриятлар эшли. Күп санда, әзер булмаган укучыларның башларын әйләндерә торган зур хаталы гарәп иншалары тәрҗемәләре бастырыла. Шуңа күрә армый кабатлыйм: профессионал ислам белгечләрен әзерләргә кирәк.

- *Минем аңлавымча, андый белем дигәч, бигрәк тә, мөселман булмаганнар күздә тотыла, чөнки мөселманнар, гадәттә, мөселман булмаган профессионал көнчыгышны белүчегә түгел, ә белемгә сай булган имамга мөрәҗәгать итүне уңайрак күрәләр.*

- Әйе, бу күңелсез күренеш булса да, шулай. Әйдәгез, ислам уку йортларында бирелә торган белемгә игътибар итик. Анда Коръән, хәдисләрне ятлыйлар, мөселман хокукын өйрәнәләр. Бөтен программа ислам динендә, хәзергәчә яшәп килгән, мәгълүм дүрт мәзһәбкә нигезләнеп бирелә: хәнәфи, шафигыйләр, маликиләр, хәнбәлиләр. Билгеле бер дәвердә һәм билгеле бер географик мохитта Изге текстны аңлау чагылган, шул ук Коръән тәрҗемәләренә дә кагыла. Шулай да, мисал өчен, Нури Османов, Коръән текстларын тәрҗемә итү өстендә эшләгәндә, XII-XIII нче гасыр фарсы тәфсирләренә таяна. Андый тәрҗемәләр, мөгаен, котылгысыздыр, ләкин укучы, Коръәннең бу тәрҗемәсе аерым бер тарихи-мәдәни мохитне чагылдыруын һәм Коръән текстының төп нөсхәсен башкача аңлау мөмкинчелеген яхшы белергә тиеш.

Аннары, сөннә дини йортларын тәмамлаучылар шигыйчылык дин белгечләре хезмәтләре белән бөтенләй таныш түгелләр диярлек (мәсәлән, әл-Кулини, әт-Туси һ.б.), шул ук вакытта шигый-студентлар да сөннә хәдисләр җыентыгы хакында начар күз алдына китерәләр. Шуңа күрә мин, дини белем үзенең табигате белән бик тар холыклы дип раслыйм, ә исламны өйрәнү мәсьәләләрен өйрәнүче дәүләт институты дөньяви булырга тиеш. Андый институт тикшеренү эшләре, фәнни тәрҗемәләр һәм комментарияләр белән генә шөгыльләнмичә, белгечләр әзерләү, ислам мәдәнияты тарихын укыта торган югары уку йортларында кулланырлык уку программалары һәм дәреслекләр әзерләр иде.

- *Минем белгәнемчә, Ломоносов исемендәге МДУ каршындагы Азия һәм Африка илләре Институтында исламны өйрәнү өлкәсендә белгечләр әзерли торган махсус үзәк бар.*

- Мин аларның 2001 нче елда чыккан махсус курслар программасының җыентыгын күрдем. "Исламны өйрәнү" программасының авторы С.А. Кириллина безнең тарафтан әзерләнгән программаны структуралы һәм эчтәлекле эшкәртеп алып бара: аның академик стилен гадиләштереп, социологик һәм илне өйрәнү темалары белән "аралаштыра". Кулланылган әдәбият исемлегендә, үзенең "иҗади дәрте" чыганагы булып торган безнең программаның күрсәтелмәве, күрәсең, юкка түгелдер. С.А. Кириллина тарафыннан

бастырылган программаның бер бүлеге "Ислам – бердәм, ислам – региональ" дип атала. Нәкъ шундый ук исем астында, 1994 нче елда, исламны өйрәнүдә яңа методологик карашлар белән, минем мәкаләм чыкты. Әгәр фәнни этиканы бу программаны төзүченең намусына калдырсак та, студентлар ислам турында системалы белем алсыннар өчен, бу программа буенча профессионал ислам белгечләре укытырга тиеш.

Берничә ел элек мин, билгеле бер максатны күздә тоткан, комплекслы "Ислам Россиядә" дигән программа төзедем. Программада профессионал ислам белгечләрен әзерләү буенча анык тәкъдимнәр күрсәтелгән. Шулай ук бу программага исламны өйрәнү академик Институтын төзү мөһимлеге турында пункт кертелде. Әгәр андый Институт төзелсә дә, анардан бары тик функционерлар һәм хакимияткә якын кешеләр генә файдаланачакларын беләм мин. Институт эшенең нәтиҗәләре, әлбәттә, күренмәячәк... Биредә бит зур дәүләт кызыксынучанлыгы бар.

Безгә, һәрвакыттагыча, тиз һәм шунда ук булсын. Югары ранг хезмәткәрләре һәм "ислам белеме генераллары" болай диләр: "Без Россиядә һәм Германиядә ислам мәсьәләләре буенча халыкара конференция үткәрергә кирәкле чаралар табарга әзер, тәҗрибә уртаклашырга немец белгечләрен чакырыйк". Бу безгә нәрсә бирәчәк?-дип сорыйм мин. Россиядә ислам – төп халкының дине, ә Германиядә - күчеп килгәннәрнеке. Безне төрле мәсьәләләр борчый. Бу – уйламый акча түгү, "күз буяу" өчен генә үткәрелгән чара.

- *Станислав Михайлович, "Элеккеге Россия империясе территориясендәге ислам" сүзлегенә кабат әйләнеп кайтып, шуны сорыйсым килә: россия мөселманнары кайчан яхшырак яшәгәннәр - империя чорындамы, яисә хәзерме? Аларның кайчан хокуклары күбрәк иде?*

- Россия империясе вакытында мөселманнарның статусы закон нигезендә тәртипкә салынып торган. Мөселманнарга, үзләрен дәүләтнең тигез хокуклы гражданнары итеп сизсеннәр дип, гыйбадәткә, дини белемгә кагылышлы күп мәсьәләләрне хәл итүдә махсус хокук, автономия бирелгән. Патша хакимияте мөселманнарга кагылышлы булган үзәк хакимият хокукларының бер өлешен мөселман дин башлыкларына тормышка ашырырга мөмкинчелек бирә. Әкренләп, югарыда утыручы мөселман дин башлыклары мохтаҗлыкта яшәүче гади халык мөрәҗәгатьләренә колак салмый башлыйлар, шуңа күрә мөселманнарның күпчелеге җәмгыятьтәге революцион үзгәрешләрне хуп күрәләр. Революция һәм аның артыннан килүче совет хакимиятенең дингә каршы сәясәте, мөселманнарны аерым статусларыннан мәхрүм итеп, хокук ягыннан бөтен халыкны тигезли.

Империя сәясәтенең, совет чорында да дәвам иткән тискәре ягы да була. Ул – көчләп руслаштыру.

Безнең чорга килгәндә, Конституция, Россиянең барлык гражданнарына, кайсы дингә ышануларына карамастан, тулы хокук бирә. Ләкин, билгеле булганча, бу хокуклар һәрвакытта да кирәгенчә үтәлми һәм Россиянең мөселман халкы капма–каршы көчләрнең бәрелешенә һәм үзәк хакимиятнең тышкы сәясәтенә бик сизгер илтифат итә (рухи планда аның тышкы мөселман дөньясы белән элемтәсе саклана). Хәзерге шартларда ислам турында фәнни белемнең әдәпле, нәзакәтле пропагандасы – Россиядә этно-конфессиональ килешүләрне булдыру юлында мөһим адым. Шул очракта гына барлык Россия гражданнары, нинди дин тотуларына карамастан, үзләрен ирекле һәм уңайлы хис итәчәкләр.

## **"Элеккеге Россия империясе территориясендәге ислам"** энциклопедик сүзлеге

1998 нче елда Россия фәннәр академиясенең көнчыгышны өйрәнү Институтының Санкт-Петербург филиалында күп томлы "Элеккеге Россия империясе территориясендәге ислам" энциклопедик сүзлеген әзерләү һәм бастыру буенча сирәк очрый торган проект тормышка ашырыла башлый. Проектның җитәкчесе, төзүчесе һәм җаваплы сәркатибе С.М. Прозоров. Бүгенге көндә "Көнчыгыш әдәбияты" (Мәскәү) нәшрияты фирмасы ярдәмендә 1-3 нче чыгарылышлары бастырылды (быел 4 нче чыгарылышы дөнья күрәчәк).

Чыгарылышларны әзерләүдә 11 илдән 60 тан артык автор катнашты. Дүрт чыгарылыш Урта (Үзәк) Азия, Татарстан, Төньяк Кавказ, Башкортостан территориясендәге исламга багышланган, әлифба тәртибендә урнашкан, 340 мәкаләне үз эченә ала. Мәкаләләрнең эчтәлеге – эре тарихи-мәдәни регионнарда ислам; шәхесләр (мөселман галимнәре, суфыйлар, шагыйрь-мистиклар, дини-сәяси эшлеклеләр, төрле дини-хокук мәктәпләре һ.б.); гыйбадәт урыннары һәм корылмалары; бәйрәмнәр, дини йолалар, мөселман гореф-гадәтләре; Коръән һәм аның Россиядә яшәеше; дин җитәкчеләренең структурасы; мөселман белем мәктәпләре; оешмалар, институтлар, төрле хәрәкәтләр; халыклар һәм этник төркемнәр; атамалар һәм исемнәр (ишан, имам, туй, пәрәнҗә) һ.б. Хронологик кысалары – күрсәтелгән территорияләрдә ислам барлыкка килүдән алып, бүгенге көнгә кадәр.